Ф.И.Габидуллина, ф.ф.к., доценты
КФУның Алабуга институты, Алабуга

# Хәзерге әдәбиятта сугыш темасы (Ф.Сафин иҗаты мисалында)

# Темы войны в современной литературе (на примере творчество Ф.Сафина)

Әлеге мәкаләдә күренекле татар язучысы Ф.Сафинның "Биек тауның башларында" романы анализлана. Романда төп игътибар сугыш темасының бирелешен ачыклауга, солдатларның батырлыгын гына түгел, ә кешелеклеген ачыклауга юнәлтелә.

Ачкыч сүзләр: татар әдәбияты, тема, сугыш, солдат, кешелеклелек.

В статье анализируется роман известного татарского писателя Ф.Сафина «На вершине высокой горы». Особое внимание уделяется описанию войны. В романе показаны не просто солдаты, а люди, проверяемые суровыми обстоятельствами не только на боевое мужество и воинское умение, но и на человечность, на нравственную стойкость.

Ключевые слова: татарская литература, тема, война, солдат, человечность.

Татар халкының тормышы беркайчан да болытсыз булмый: үзара тартышлар, фетнәләр, сугышлар һәр буын кешесенә диярлек авыр сынаулар китерә. Әмма егерменче гасырның беренче яртысында яшәгәннәргә аеруча күп кайгы-хәсрәт, авырлыклар кичерергә туры килә. Бу чорда дүрт сугыш һәм өч инкыйлаб була [1, 216 б.].

Татар әдәбиятының һәр чорында сугыш темасы традицион темаларның берсе булган. Әдипләребез кешеләрнең рухи ныклыгын, оптимистик табигатен сурәтлиләр, бер үк вакытта теләсә нинди сугышның кешелеккә бары кайгы-хәсрәт кенә китергәнен расларга омтылалар. Мәсәлән, Ф.Сафинның "Биек тауның башларында" (1999) [3, 240 б.] романын гына алыйк. Әсәрдә сүз туксанынчы елларда күпләребезнең бәгырьләрен телгәләгән фаҗига –

мәгънәсез Чечен сугышы, әле үсмерлекләреннән дә чыкмаган егетләребезнең һәлак булулары, армия хәлләре, экстремаль ситуацияләрдә адәм балаларының бер-берсенә мөнәсәбәтләре, беренче мәхәббәт өзгәләнүләре тасвирлана...

Гадел хезмәт белән көн итүче авыл кешеләре гаиләсендә туып-үскән, үз гомерендә әле авылыннан башка бүтән җир күрмәгән Шәфкать, гаскәри хезмәткә алына. Анда кырыс чынбарлык белән йөзгә-йөз очраша.

Юк, ул авылын, әнисен, әле унсигез яше дә тулмаган, кичтән генә өйләнеп киткән (мулла никахы белән генә) хатынын сагынып елап утырмый. Күңеленең үксүе бүтәннән, кешеләрнең бер-берсенә булган каты бәгырьлелегеннән, миһербансызлыгыннан чарасыз ул. Аның авылы кешеләре мондый түгел бит! Туры сүзле, каты куллы, гадел – тик миһербансыз түгелләр.

Һәрби хезмәтнең беренче көнендә үк солдатларны генерал Головастиков каршы ала. "Сезнең өчен Алла да, генерал да – мин! – диде ул. Аның тавышы ачыктан-ачык кисәтүле иде.

- Минем боерыктан башка колак яфрагы да селкенергә тиеш түгел! Башыгызда бер бөртек чәч күрмим – чүлмәкләрегез тап-такыр итеп алдырылган булырга тиеш. Теләсәм...

Ул бар көченә каршысында торган солдатның эченә китереп төртте. Солдат ухылдап ауды һәм авыртуга чыдый алмый, тартыша башлады. Головастиковның йөзенә кыргый тантана бәреп чыкты.

- Теләсәм – менә шулай бу-ла-чак! Аңладыгызмы?! [3, 110 б.]. Шәфкать өчен китаплардан укып күзаллаган армия булмый бу. Монда бүреләр законы хакимлек иткәнен ул бик тиз арада аңлап ала. "Әмма нишлисең, өйгә кайтып китеп булмый, хезмәт итәргә кирәк"?.

Ә көннәрдән бер көнне солдатларны чичен сугышына җибәрәчәкләре мәгълүм була. Командирлар солдатларда чичен халкына нәфрәт уятыр өчен бар көчен куялар, төрле мисаллар китерәләр. "Солдатларны ашыктыра-ашыктыра сафка тезделәр. Саф каршына тартма кырлары ачылган КамАЗ машинасы килеп туктады. Тартмага җиңел гәүдәле ике кеше сикерешеп менделәр. Тартма сәхнә рәвешен алды да куйды. Сәхнә уртасында эченә нидер салынган капчык.

Беренче мәлдә иң гаҗәпләндергәне шул булды –хәрби комуфляжлы бу кешеләр йөзләрен кара япма белән ябып, томалап куйганнар иде. Япмадагы йомры тишекләрдән күзләре генә елтырап тора. Алар зур эш башкарган кешеләр сыман, каударланмыйча гына, капчыкның авызын чиштеләр, эчендәге нәрсәләрне сак кына тартма төбенә бушаттылар. Саф өстеннән "чатырдап" килеп яшен уйнап үттемени – барысы берьюлы "аһ" итеп җиргә чүгеп куйдылар. Шәфкатьнең аңы томаланды – тартма төбендә кисеп алынган кеше башлары тәгәрәшеп ята иде. Өчәү иде булса кирәк...” [3, 118 б.].

Башта бик күпләр кебек үк, Шәфкать тә үзләрен ашыгыч рәвештә җылы ояларыннан кубарып алып, шушы ачык кырга китереп бушатуның, соңгы көннәрдә Чичен иленә, чичен халкына каршы кеше ышанмастай коткы таратуларның төп сәбәбен белеп бетерми. Сугышка Шәфкать танк йөртүче булып китә, әмма сугыша алмый яраланып госпитальгә эләгә.

Раушания иренең Чечен илендә әсирлектә икәнен телевизордан күреп белә. "Хәкимә Раушаниянең алдына килеп басты, сүзен әйтә алмый интекте, аннан үзәк өзгеч тавыш белән:

- Шәфкать... Шәфкатемне күрдем! – дип кычкырып җибәрде.

- Шәфкатьне? – Раушаниянең күзләре зур булып ачылды.

- Кайда ул?

- Ничек?..

- Телевизорда. Пленга эләккән, бичаракаем. Үз күзләрем белән күрдем. Шунда ята, аягы кан гына" [3, 118 б.].

Бу хәбәрдән соң Раушания юлга кузгала. Юлда ул Сөләйман исемле чичен егете белән таныша. Сөләйман әти-әнисен, туганнарын дошман һөҗүменнән якларга, Раушания исә "дошман булып басып кергән", әсирлеккә төшкән ирен коткарырга ашыга. Хәтергә уелырлык күренеш. Кешене хәсрәт якынайта диләр, алар да бер-берсенә ярдәм итеп, терәк булып сугыш барган җиргә ашыгалар. Алар бер-берсенә дошман итеп карамыйлар, чөнки икесе дә бу очракта корбаннар. Мәгънәсез чичен сугышының "бүленмәс" империянең корбаннары. Нәкъ шушы урында чичен егете Сөләйман образын әсәргә кертүе – авторның

уңышлы алымы.

Чечен иленә килеп җитүгә Раушания Шәфкатьне эзләп госпитальгә килә, анда бер яралы солдаттан Шәфкатьнең исән икәнен белә. Госпитальдә моңа кадәр күрмәгәннәрне күрә Раушания, бу мәгънәсез сугышта яраланган, үлгән кешеләр монда бихисап була. Мең газаплар белән килеп җитеп, ирен таба алмый тилмереп йөргәндә, яралыларга ярдәм итү йөзеннән, пулялар яңгыры астында чиләк тотып суга барырга чыккан җиреннән Раушания дә Шәфкать танкыннан корбан булырга тиеш була. Чөнки капитан Хасистовның боерыгы шундый: "юлда очраган бер генә җан иясен дә аямаска" [3, 212 б.]. "Юлны очраклы кисеп чыгучы тагын бер кеше күренде. Хатын-кыз. Ул кулларын як-якка җәеп агач төбендә яткан яралыга ташланды. Шулай ук кулында нәрсәдер бар. Хәзер инде ачык шәйләде Шәфкать, шартлаткыч дип шикләнгәне чиләк булып чыкты" [3, 213 б.].

Күңеле, җан һәм тән берлеге үзен сиздергәндер күрәсең, Шәфкать төтен арасындагы шәүләнең Раушания икәнлеген таныганнан соң танкын калдырып аңа ташлана. "Шәфкать күзләрен шытырдап йомды, тагын ачты, баш миенең почмагында сәер уйлар тезмәсе йөгерешә башлады: "Тукта, каршыңда Раушания басып тора бит, туктат бу тимер тавыңны. Йөгереп бар, күтәреп ал хатыныңны" [3, 213 б.]. Ә бу вакытта Усаклыга Чечен илендә һәлак булган, янып кара күмергә әйләнгән, танымаслык хәлгә килгән егетне кургаш табутта кайтаралар. "Абзый кеше, мондый чакта эмоциягә артык бирелмәскә киңәш итәм. Беләм, аңлыйм, сезгә бик авыр мондый хәбәрне ишетүе. Әмма әйтмичә чара юк. Сезнең улыгыз, рядовой Шәмсетдинов Шәфкать хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган..." [3, 231 б.]. Бу табутта Шәфкать ятканын белгәч Хәкимә апа шашар дәрәҗәгә җитә.

" – Түгел, Гасыймкаем, минем улым түгел бу. Бөтенләй башка кеше ята бит. Ник дәшмисең ?.." [3, 234 б.]. Ана күңеле ялганламый. Табутта – аның улы урынында, частька килгәннең беренче көннәреннән үк Шәфкатькә күп кыерсыту, җәбер күрсәткән капитан Хасистов гәүдәсе..." [3, 234 б.].

Бу хәлләрдән соң бераз вакыт үткәч Усаклыга Шәфкатьнең хаты килә. "Мин

исән. Саулык кына чамалы. Чөнки Чечен илендә барган сугышта катнашырга туры килде миңа. Раушания белән Грозныйда очраштык. Ничек очраштык, башта ниләр кичте – барысы турында да очрашкач сөйләшербез. Хатка язып кына бетермәле түгел. Әмма шуны гына әйтә алам. Әгәр Раушания булмаса, мин исән калмас идем" [3, 238 б.].

Үлем яхшы кешеләрне генә сагалап йөри дисәк тә, яхшы кешеләрне читләтеп тә үтә икән. Чөнки алар – Шәфкать белән Раушания, яшәргә хөкем ителгәннәр, алар бит бу дөньяда бәхетле булырга килгәннәр...

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: "Биек тауның башларында" әсәре, беренче карашка, гап-гади авылның гадәти кешеләре турында. Әмма вакыйгалар агышына керә барган саен, әсәрнең мәгънәсе тирәнәя, асыл максатның җегәре саллылана баруын тоясың. Әсәр – яшәү белән үлем хакындагы мәңгелек фәлсәфәгә нигезләнгән. Әдип әсәрендә чичен сугышының мәгънәсез булуын тагын бер кат исбатлый. Кисеп ташланган кеше башлары, бер гөнаһсызга үтерелгән сабыйлар моның ачык мисалы. Бу сугыш кемнәрнеңдер гомерлек йөрәк ярасы булып калды. Шушы мәгънәсез сугышта меңләгән аналарның күз карасыдай саклап, кадерләп үстергән газиз балалары вафат булды.

Ф.Сафин әлеге романда меңләгән яшьләрнең язмышын Шәфкать, Раушания, Сөләйман, Хәкимә кебек образларда күрсәтә. Ул укучыны геройлар язмышы турында билгесезлектә калдырып әлеге сугышның күпме афәт китергәнен, күпме  яшьләренең гомере өзелгәнен тасвирлап, аналарның хәсрәтен тирәнрәк тоярга булыша.

## ӘДӘБИЯТ


1. Бәширов Ф. К. XX йөз башы татар прозасы . – Казан: Фикер, 2002.
2. Закирҗанов Ә. Онытырга хакыбыз юк // Казан утлары. – 2000. – №8.
3. Сафин Ф. Биек тауның башларында – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.
4. Хатипов Ф., Сверигин Р. Әмирхан Еники иҗатының поэтик аһәңнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.